Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LI-3**

Балык Бистәсе штп. 2024 елның 22 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге XXXI-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 маддәләре, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2023 елның 29 августындагы 10-53/10582 номерлы уңай бәяләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге XXXI-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына (15.07.2016 ел №XI-5, 16.11.2016 ел №XIII-8, 29.12.2018 ел №XXXVIII-3, 15.11.2023 ел №XLIII-4 карарлар редакциясендә) Полянка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Полянка авылы чикләре турында мәгълүматларны өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Башлык Р.Р. Ислямов